КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 23 апрель г.Казань № 331

Акцияләрнең (өлешләрнең) 100 проценты Татарстан Республикасыныкы булган юридик затлар милкендә булган капиталь төзелеш объектларына һәм (яки) алар тарафыннан күчемсез милек объектларын сатып алуга капитал салуларны гамәлгә ашыруга, алга таба мондый юридик затларның устав капиталларын Россия Федерациясе законнары нигезендә арттыру белән күрсәтелгән юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү турында карар кабул итү кагыйдәләрен раслау хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясындагы 8 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Акцияләрнең (өлешләрнең) 100 проценты Татарстан Республикасыныкы булган юридик затлар милкендә булган капиталь төзелеш объектларына һәм (яки) алар тарафыннан күчемсез милек объектларын сатып алуга капитал салуларны гамәлгә ашыруга, алга таба мондый юридик затларның устав капиталларын Россия Федерациясе законнары нигезендә арттыру белән күрсәтелгән юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү турында карар кабул итү кагыйдәләрен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Икътисад, финанслар һәм дәүләт мөлкәте белән эш итү идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин